| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 ноября 2020 г. с.Шалты № 15

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

2020 елның 27 ноябренә 14:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Совет урамы, 63Б адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару

буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

- Шалты авылы урамнарын кардан һәм чүп үләннәреннән чистарту

- ЭЦВ (6-10-80 4 КВт) насосы һәм GP су насосы сатып алу

- Су үткәргеч челтәрен ремонтлау өчен запас частьләр (муфталар, краннар, сгоннар, хомутлар, гайкалар, болтлар, электродлар) һәм су алу колонкалары (КВ-4) сатып алу

- Каптажлы чишмәнең коймасын төзекләндерү

2. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шалты авыл
җирлеге Башлыгы З.Х. Фаткуллин